Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елның 23 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Прости авыл җирлегендә халык җыены хәл ителде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда гражданнардан үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче гражданнарның, көндезге бүлектә белем алучы студентларның гаилә әгъзаларын; 2 төркем инвалидлар 50 процент күләмендә түләүне башкаралар.
2. Алган акчаларны торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга (Кайманов урамыннан юл полотносын Подгорная урамы юнәлешендә ремонтлау) җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Прости авыл җирлеге башлыгы Д.А. Бәдәртинов